**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 9 июнендәге 1958 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2016 елның 18 гыйнварындагы 33 номерлы карары белән расланган «Юбилей станциясе» территориясен планлаштыру һәм ызанлау проектына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 42, 45, 46 статьялары нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 2 февралендәге 112 номерлы «Федераль башкарма хакимиятнең вәкаләтле органнары, вәкаләтле Россия Федерациясе субъектларының башкарма органнары һәм җирле үзидарә органнары карарлары нигезендә әзерләнә торган территорияне планлаштыру документларын әзерләү, территорияне планлаштыру документларын раслау турында карар кабул итү, мондый документларга үзгәрешләр кертү, мондый документларны яки аның аерым өлешләрен гамәлдән чыгару, мондый документларның аерым өлешләрен кулланылырга тиеш түгел дип тану, шулай ук федераль һәм төбәк әһәмиятендәге тарихи җирлекләр территорияләренә карата территорияне планлаштыру проектын әзерләү һәм раслау кагыйдәләрен раслау турында»гы карары буенча **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2016 елның 18 гыйнварындагы 33 номерлы карары (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2025 елның 13 августындагы 2634 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган «Юбилей станциясе» территориясен планлаштыру һәм ызанлау проектына, территорияне планлаштыру проектының аерым өлешләрен әлеге карарга кушымта нигезендә раслап, үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан

Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары А.Р.Нигъмәтҗановка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның 9 июнендәге
1958 номерлы карарына
кушымта

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2016 елның 18 гыйнварындагы 33 номерлы карары белән расланган**
**«Юбилей станциясе» территориясен планлаштыру һәм ызанлау**
**проектына кертелә торган үзгәрешләр**

1. I «Җирле әһәмияттәге капиталь төзелеш объектларын урнаштыру, шулай ук территорияне план буенча үстерү характеристикалары, шул исәптән территориядәге төзелешнең тыгызлыгы һәм параметрлары, территорияне үстерү өчен кирәкле социаль, транспорт хезмәте күрсәтү һәм инженерлык-техник яктан тәэмин итү системаларын үстерү характеристикалары турында нигезләмә» бүлегендә:

1.1. 1 «Капиталь төзелеш объектларын урнаштыру, территорияне план буенча үстерү характеристикалары» пунктында:

1.1.1. 1.1 «Территория балансы (проект нигезләмәсе)» таблицасында:

1.1.1.1. 9 юлны түбәндәге редакциядә бирергә:

| **№ т/б** | **Территориянең исеме** | **Га** | **%** |
|---|---|---|---|
| «9 | гомуми файдаланудагы яшел үсентеләр зонасы | 3,78 | 6,66» |

1.1.1.2. 10 юлга түбәндәге эчтәлекле юллар өстәргә:

| **№ т/б** | **Территориянең исеме** | **Га** | **%** |
|---|---|---|---|
| «10 | урам-юл челтәрен урнаштыру территорияләре | 5,91 | 10,42» |

1.1.2. 1.2 «Җир кишәрлекләрендә капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзүнең чик параметрлары» таблицасында:

1.1.2.1. «Рөхсәт ителгән файдалану төрләре коды» баганасында 4, 5, 6, 10, 16, 21, 22 юллардагы «4.9.2» саннарын төшереп калдырырга;

1.1.2.2. «Зона мәйданы, га» баганасында «1,92» саннарын «0,66» саннарына алмаштырырга;

1.1.2.3. «Урнаштырыла торган объектлар турында мәгълүмат» баганасында 1 юлда «Р-1 бульвары» сүзләрен «Р-1 бульварының 1 өлеше» сүзләренә алмаштырырга;

1.1.2.4. «Урнаштырыла торган объектлар турында мәгълүмат» баганасында 6 юлда «2500 урын» сүзләрен «2119 урын (1501 урынлык 1 корпус, 618 урынлык 2 корпус)» сүзләренә алмаштырырга;

1.1.2.5. түбәндәге эчтәлекле юллар өстәргә:

| **Зонаның тәртип номеры** | **Зона төре номеры** | **Капиталь төзелеш объектларын урнаштыру зонасы төре** | **Рөхсәт ителгән файдалану төре коды** | **Зона мәйданы, га** | **Торак фондының (фатирларның) максималь гомуми мәйданы, мең кв.м** | **Капиталь төзелеш объектларының максималь катлары саны** | **Капиталь төзелеш объектларын урнаштыру зонасы чикләрендә торак фондының (фатирларның) максималь тыгызлыгы, мең кв.м/га** | **Торак булмаган билгеләнеш тәге бүлмәләрнең гомуми мәйданы, мең кв.м** | **Урнаштырыла торган объектлар турында мәгълүмат** |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «24 | 4 | Гомуми файдаланудагы яшел үсентеләр зонасы, гамәлдәге | 3.1.1, 12.0.2 | 1,20 | Билгеләнмәгән | Билгеләнмәгән | Билгеләнмәгән | Билгеләнмәгән | Р-1 бульварының 2 өлеше |
| 25 | 8 | Урам-юл челтәрен урнаштыру зонасы, планлаштырыла торган | 3.1.1, 4.9.2, 12.0.1 | 0,06 | Билгеләнмәгән | Билгеләнмәгән | Билгеләнмәгән | Билгеләнмәгән | Парковкалар урнаштырылган урам-юл челтәре» |

1.2. 2 «Социаль хезмәт күрсәтү системаларын план буенча үстерү характеристикалары, төзелеш параметрлары» пунктында:

1.2.1. икенче абзацны түбәндәге редакциядә бирергә:

«Планлаштыру проекты территориясендәге фаразланган халык өчен мәктәпкәчә балалар учреждениеләрендә һәм гомуми белем бирү мәктәпләрендә урыннарның тиешле саны Казан шәһәре Думасының 2016 елның 14 декабрендәге 8-12 номерлы карары белән расланган Казан шәһәр округының шәһәр төзелешен проектлаштыруның җирле нормативларындагы (үзгәрешләрне исәпкә алып) 6.2.4 пункты һәм 5.1.1.1.1 таблицасы нигезендә белем бирү оешмаларында урыннар белән тәэмин ителешне исәпләп чыгару методикасы нигезендә исәпләнә»;

1.2.2. өченче абзацта:

1.2.2.1. «27 урын» сүзләрен «24 урын» сүзләренә алмаштырырга;

1.2.2.2. «57» санын «47» санына алмаштырырга;

1.2.3. дүртенче абзацта:

1.2.3.1. «1539» санын «1369» санына алмаштырырга;

1.2.3.2. «3249» санын «2680» санына алмаштырырга;

1.2.4. бишенче абзацта:

1.2.4.1. «3724» санын «3343» санына алмаштырырга;

1.2.4.2. «464» санын «383» санына алмаштырырга;

1.2.5. 2.1 «Территорияне планлаштыру проекты нигезендә белем һәм тәрбия бирү объектлары» таблицасында:

1.2.5.1. «Балалар бакчалары» бүлегендә «Исәпләү буенча ихтыяҗ, урын» баганасында, «Барлыгы» юлында «1539» санын «1369» санына алмаштырырга;

1.2.5.2. «Гомуми белем бирү мәктәпләре» бүлегендә «Егәрлек, урын» баганасында, 1 юлда «2500» санын «2119*» санына алмаштырырга;

1.2.5.3. «Гомуми белем бирү мәктәпләре» бүлегендә «Барлыгы» юлын түбәндәге редакциядә бирергә:

<table>
<tr><th rowspan="2">№ т/б</th><th rowspan="2">Барлы гы</th><th rowspan="2">Исәпләү буенча ихтыяҗ, урын</th><th colspan="3">Урнаштыру</th></tr>
<tr><th>Билгеләнеше</th><th>Егәрлек, урын</th><th>Җир кишәрлекләре үлчәмнәре, га</th></tr>
<tr><td colspan="2">«Барлыгы</td><td>2680 + 383 («Времена года» торак комплексы өчен) = 3063</td><td></td><td>3343</td><td>6,92»</td></tr>
</table>

1.2.5.4. таблицадан соң түбәндәге эчтәлекле искәрмә өстәргә: «* Ш-1 мәктәбе ике корпустан тора: 1501 урынлык 1 корпус, 618 урынлык 2 корпус»;

1.2.6. 2.2 «Территорияне планлаштыру проекты чикләрендә яңа төзелешкә хезмәт күрсәтүнең аерым торучы объектлары» таблицасында «Исеме» баганасының 1 юлында «2500 урын» сүзләрен «2119 урын (1501 урынлык 1 корпус, 618 урынлык 2 корпус)» сүзләренә алмаштырырга, «Егәрлек» баганасында «2500» санын «2119» санына алмаштырырга;

1.3. 3 «Транспорт белән тәэмин итү системасы үсеше характеристикалары» пунктында 3.2 «Автомобильләрне саклау һәм кую урыннарын төзү» пунктчасында:

1.3.1. өченче абзацта «50» санын «80» санына алмаштырырга;

1.3.2. өченче абзацтан соң түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Казан шәһәре Думасының 2016 елның 14 декабрендәге 8-12 номерлы карары белән расланган Казан шәһәр округының шәһәр төзелешен проектлаштыруның җирле нормативларының (үзгәрешләрне исәпкә алып) 5.2.7.3.1 таблицасына нигезләнеп, гомуми белем бирү учреждениеләре өчен 5 хезмәткәргә 1 машина урынын булдыруны күздә тотарга кирәк. Килүчеләр өчен автомобиль кую урыннары җир кишәрлегеннән читтә, урам-юл челтәренең кызыл линияләрендә машина юлы киңәйтелгән урыннарда яки махсус бүленгән җир кишәрлегендә урныштырылырга тиеш.

251.1325800.2016 номерлы кагыйдәләр җыелмасының 6.4.2 «Гомуми белем бирү оешмалары. Проектлаштыру кагыйдәләре» пункты нигезендә гомуми белем бирү оешмасының үз территориясе киртәсе артында балаларын мәктәпкә алып килүче ата-аналарның автотранспортын кыска вакытка куеп тору өчен урыннар карау рөхсәт ителә. Әлеге урыннар саны проектлаштыруга бирем буенча билгеләнә, 100 укучыга бер машина урыны, шул исәптән халыкның хәрәкәтләнүе чикле төркеме өчен кимендә бер зурайтылган урын кабул итәргә киңәш ителә.

Гомуми белем бирү оешмалары өчен барлыгы 106 машина урыны, шул исәптән халыкның хәрәкәтләнүе чикле төркеме өчен 9 машина урыны кирәк.

Казан шәһәре Думасының 2016 елның 14 декабрендәге 8-12 номерлы карары белән расланган Казан шәһәр округының шәһәр төзелешен проектлаштыруның җирле нормативларының (үзгәрешләрне исәпкә алып) 5.2.7.3.1 таблицасына нигезләнеп, мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре өчен 7 хезмәткәргә 1 машина урынын булдыруны күздә тотарга кирәк. Килүчеләр өчен автомобиль кую урыннары җир кишәрлегеннән читтә, урам-юл челтәренең кызыл линияләрендә машина юлы киңәйтелгән урыннарда яки махсус бүленгән җир кишәрлегендә урнаштырылырга тиеш.

Мәктәпкәчә белем бирү оешмалары өчен барлыгы 46 машина урыны, шул исәптән халыкның хәрәкәтләнүе чикле төркеме өчен 5 машина урыны кирәк»;

1.3.3. 3.1 «Парковка урыннарының кирәкле санын исәпләү» таблицасын түбәндәге редакциядә бирергә:

«3.1 таблица

**Парковка урыннарының кирәкле санын исәпләү**

| № т/б | Парковка урыннары кирәк булган объектлар | Казан шәһәр округының шәһәр төзелешен проектлаштыруның җирле нормативлары буенча норма | Исәпләү өчен күрсәткечләр | Машина урыннарының кирәкле саны |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Торак йортлар, даими саклау өчен парковка урыннары | Фатирларның гомуми мәйданының 80 кв. метрына 1 машина урыны | 570047,09 | 7131 |
| 2 | Торак йортлар, килүчеләр өчен автомобиль кую урыннары | Фатирларның гомуми мәйданының 560 кв. метрына 1 машина урыны | 570047,09 | 1023 |

| № т/б | Парковка урыннары кирәк булган объектлар | Казан шәһәр округының шәһәр төзелешен проектлаштыруның җирле нормативлары буенча норма | Исәпләү өчен күрсәткечләр | Машина урыннарының кирәкле саны |
|---|---|---|---|---|
| 3 | Торак зонасында автомобильләр өчен электр энергиясен җыю станцияләре | Фатирларның гомуми мәйданының 10 кв. метрына 1 машина урыны | 570047,09 | 60 |
| 4 | Торак булмаган билгеләнештәге кертеп-кушып төзелгән биналар (иҗтимагый билгеләнештәге биналар) | 80 кв.м мәйданга 1 машина урыны | 53468,27 | 673 |
| **Күпкатлы торак төзелеше зонасы буенча барлыгы** | | **8887 машина урыны, шуларның 887 машина урыны – халыкның хәрәкәтләнүе чикле төркеме өчен һәм 163 машина урыны – коляскадагы инвалидлар өчен** | | |
| 5 | ОД-1 күпфункцияле сәүдә үзәге | 50 кв.м мәйданга 1 машина урыны | 4500 | 90 |
| 6 | ОД-1 сәүдә үзәге территориясендә автомобильләр өчен электр энергиясен җыю станцияләре | 1000 кв.м мәйданга 1 машина урыны | 4500 | 5 |
| **Иҗтимагый-эшлекле билгеләнеш зонасы буенча барлыгы** | | **95 машина урыны, шуларның 5 машина урыны – халыкның хәрәкәтләнүе чикле төркеме өчен һәм 5 машина урыны – коляскадагы инвалидлар өчен** | | |
| 7 | Мәктәпкәчә белем бирү оешмалары | Исәпләнгән персоналның 7 эш урыны өчен 1 машина урыны | 308 | 46 |
| 8 | Гомуми белем бирү мәктәпләре | Исәпләнгән персоналның 5 эш урыны өчен 1 машина урыны 100 укучыга 1 машина-урын | 342 | 106 |
| **Уку-укыту һәм белем бирү билгеләнешендәге зона буенча барлыгы** | | **152 машина урыны, шуларның 14 машина урыны – инвалидлар өчен** | | |
| **Барлыгы** | | **9134 машина урыны, шуларның 910 машина урыны – инвалидлар өчен, 168 машина урыны – коляскадагы инвалидлар өчен»** | | |

1.3.4. 3.2 «Торак фонды өчен парковка урыннарының кирәкле санын исәпләү» таблицасын түбәндәге редакциядә бирергә:

«3.2 таблица

**Торак фонды өчен парковка урыннарының кирәкле санын исәпләү**

| № т/б | Эшләтеп җибәрү комплексы номеры | Торак фонды мәйданы, кв.м | Торак булмаган билгеләнештәге кертеп-кушып төзелгән биналар мәйданы (иҗтимагый билгеләнештәге биналар) | Парковка урыннарын исәпләү | | | Парковка урыннарының исәпләнгән саны | | | Торак фонды автомобильләре өчен электр энергиясе җыю станцияләре булган парковка урыннары (10 мең кв.м гомуми фатир мәйданына 1 машина урыны) | Электр энергиясе җыю станциясе булган урыннарны исәпкә алып, барлык парковка урыннары |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Даими саклау өчен парковка урыннары (фатирларның гомуми мәйданының 80 кв. метрына 1 машина урыны) | Килүчеләр өчен парковка урыннары (фатирларның 560 кв.м гомуми мәйданына 1 машина урыны) | Торак булмаган билгеләнештәге эчкә кертеп-кушып төзелгән биналар (иҗтимагый билгеләнештәге биналар) өчен автомобиль кую урыннары (80 кв.м мәйданга 1 машина урыны) | Барлыгы | шуларның инвалидлар өчен | шуларның коляскадагы инвалидлар өчен | | |
| 1 | 1 нче эшләтеп җибәрү комплексы | 67262,6 | 3828,7 | 841 | 121 | 48 | **1010** | 101 | 20 | 7 | **1017** |
| 2 | 2 нче эшләтеп җибәрү | 44017,05 | 3476,4 | 551 | 79 | 44 | **674** | 68 | 16 | 5 | **679** |

| № т/б | Эшләтеп җибәрү комплексы номеры | Торак фонды мәйданы, кв.м | Торак булмаган билгеләнештәге кертеп-кушып төзелгән биналар мәйданы (иҗтимагый билгеләнештәге биналар) | Парковка урыннарын исәпләү | | | Парковка урыннарының исәпләнгән саны | | | Торак фонды автомобильләре өчен электр энергиясе җыю станцияләре булган парковка урыннары (10 мең кв.м гомуми фатир мәйданына 1 машина урыны) | Электр энергиясе җыю станциясе булган урыннарны исәпкә алып, барлык парковка урыннары |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Даими саклау өчен парковка урыннары (фатирларның гомуми мәйданының 80 кв. метрына 1 машина урыны) | Килүчеләр өчен парковка урыннары (фатирларның 560 кв.м гомуми мәйданына 1 машина урыны) | Торак булмаган билгеләнештәге эчкә кертеп-кушып төзелгән биналар (иҗтимагый билгеләнештәге биналар) өчен автомобиль кую урыннары (80 кв.м мәйданга 1 машина урыны) | Барлыгы | шуларның инвалидлар өчен | шуларның коляскадагы инвалидлар өчен | | |
| | комплексы | | | | | | | | | | |
| 3 | 3 нче эшләтеп җибәрү комплексы | 68484,08 | 12049,92 | 857 | 123 | 151 | **1131** | 114 | 21 | 7 | **1138** |
| 4 | 4 нче эшләтеп җибәрү комплекс | 14817,6 | 3142,84 | 186 | 27 | 40 | **253** | 26 | 10 | 2 | **255** |

| № т/б | Эшләтеп җибәрү комплексы номеры | Торак фонды мәйданы, кв.м | Торак булмаган билгеләнештәге кертеп-кушып төзелгән биналар мәйданы (иҗтимагый билгеләнештәге биналар) | Парковка урыннарын исәпләү | | | Парковка урыннарының исәпләнгән саны | | | Торак фонды автомобильләре өчен электр энергиясе җыю станцияләре булган парковка урыннары (10 мең кв.м гомуми фатир мәйданына 1 машина урыны) | Электр энергиясе җыю станциясе булган урыннарны исәпкә алып, барлык парковка урыннары |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Даими саклау өчен парковка урыннары (фатирларның гомуми мәйданының 80 кв. метрына 1 машина урыны) | Килүчеләр өчен парковка урыннары (фатирларның 560 кв.м гомуми мәйданына 1 машина урыны) | Торак булмаган билгеләнештәге эчкә кертеп-кушып төзелгән биналар (иҗтимагый билгеләнештәге биналар) өчен автомобиль кую урыннары (80 кв.м мәйданга 1 машина урыны) | Барлыгы | шуларның инвалидлар өчен | шуларның коляскадагы инвалидлар өчен | | |
| | ы | | | | | | | | | | |
| 5 | 5 нче эшләтеп җибәрү комплексы | 83982,25 | 6513,8 | 1050 | 150 | 82 | **1282** | 129 | 22 | 9 | **1291** |
| 6 | 6 нчы эшләтеп җибәрү комплексы | 137207,37 | 11681,08 | 1716 | 246 | 147 | **2109** | 211 | 31 | 14 | **2123** |

| № т/б | Эшләтеп җибәрү комплексы номеры | Торак фонды мәйданы, кв.м | Торак булмаган билгеләнештәге кертеп-кушып төзелгән биналар мәйданы (иҗтимагый билгеләнештәге биналар) | Парковка урыннарын исәпләү | | | Парковка урыннарының исәпләнгән саны | | | Торак фонды автомобильләре өчен электр энергиясе җыю станцияләре булган парковка урыннары (10 мең кв.м гомуми фатир мәйданына 1 машина урыны) | Электр энергиясе җыю станциясе булган урыннарны исәпкә алып, барлык парковка урыннары |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Даими саклау өчен парковка урыннары (фатирларның гомуми мәйданының 80 кв. метрына 1 машина урыны) | Килүчеләр өчен парковка урыннары (фатирларның 560 кв.м гомуми мәйданына 1 машина урыны) | Торак булмаган билгеләнештәге эчкә кертеп-кушып төзелгән биналар (иҗтимагый билгеләнештәге биналар) өчен автомобиль кую урыннары (80 кв.м мәйданга 1 машина урыны) | Барлыгы | шуларның инвалидлар өчен | шуларның коляскадагы инвалидлар өчен | | |
| 7 | 7 нче эшләтеп җибәрү комплексы | 105849,8 | 10193,74 | 1324 | 190 | 128 | **1642** | 165 | 26 | 11 | **1653** |
| 8 | 8 нче эшләтеп җибәрү комплексы | 48426,34 | 2581,79 | 606 | 87 | 33 | **726** | 73 | 17 | 5 | **731** |
| **Барлыгы** | | **570047,09** | **53468,27** | **7131** | **1023** | **673** | **8827** | **887** | **163** | **60** | **8887»** |

1.3.5. 3.2 таблицасыннан соң түбәндәге эчтәлекле таблица өстәргә:

«3.2(1) таблица

**ОД-1 күпфункцияле сәүдә үзәге өчен кирәкле парковка урыннары санын исәпләү**

| Мәйданы | Парковка урыннары ның исәпләнгән саны (50 кв.м мәйданга 1 машина урыны) | шулардан инвалид лар өчен | шулардан коляскадагы инвалидлар өчен | Автомобильләр өчен электр энергиясе җыю станцияләре булган парковка урыннары (1000 кв.м мәйданга 1 машина урыны) | Барлы гы |
|---|---|---|---|---|---|
| 4500 | 90 | 9 | 5 | 5 | 95» |

1.3.6. җиденче абзацта «2575» санын «2370» санына алмаштырырга;

1.3.7. сигезенче абзацта «2050» санын «1817» санына алмаштырырга;

1.3.8. тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бирергә:

«– 1 номерлы, 2 номерлы урамнар, Ярышлар урамы, 15 номерлы, 17 номерлы юллар буйлап 839 машина урыны сыйдырышлы ачык муниципаль парковкалар»;

1.3.9. унынчы абзацта «9440 машина урыны» сүзләрен «9134 машина урыны» сүзләренә, «948» санын «910» санына, «174 машина урыны» сүзләрен «168 машина урыны» саннарына алмаштырырга;

1.3.10. уникенче абзацны түбәндәге редакциядә бирергә:

«Белем бирү учреждениеләре объектлары өчен автомобиль парковкалары тиешле объектларга җәяү барып җитәргә мөмкин булган яссылыктагы җир өсте парковкаларында һәм ачык муниципаль парковкаларда урнаштырылган: мәктәпләр өчен 106 машина урыны – 2 номерлы урам, 1 номерлы, 2 номерлы, 12 номерлы юллар буйлап, балалар бакчалары өчен 46 машина урыны 1 номерлы, 5 номерлы, 10 номерлы, 15 номерлы, 16 номерлы юллар буйлап урнаштырылган. Торак төзелеше, торак булмаган билгеләнештәге кертеп-кушып төзелгән биналар (иҗтимагый билгеләнештәге биналар) өчен 8887 машина урыны һәм ОД-1 күпфункцияле сәүдә үзәге өчен 95 машина урыны тиешле объектларда җир кишәрлекләре өслегендә һәм/яки җир асты паркингларында, һәм/яки аерым торган ачык паркингларда, һәм/яки яссылыктагы җир өсте парковкаларында, һәм/яки ачык муниципаль парковкаларда урнаштырылган. Урнаштыру ысулы һәм урыны (ачык парковкалар, һәм/яки җир өсте паркинглары, һәм/яки җир асты паркинглары, һәм/яки стилобатлар)

проектлаштыруның алдагы этапларында билгеләнә, шул ук вакытта вакытлыча парковкаларны урнаштыру (балалар бакчасы урнаштыру өчен билгеләнгән территориядән кала) төзелешнең соңгы этапларында төзелмәгән территорияләрдә рөхсәт ителә»;

1.4. 4 «Инженерлык-техник яктан тәэмин итү системасын үстерү характеристикалары» пунктында:

1.4.1. 4.1 пунктчасында «8066,86» санын «8059,95» санына алмаштырырга;

1.4.2. 4.2 пунктчасында «6736,72» санын «6729,81» санына алмаштырырга;

1.4.3. 4.4 пунктчасында «22510,98» санын «22469,07» санына алмаштырырга;

1.4.4. 4.5 пунктчасында «8102,52» санын «7975,18» санына алмаштырырга;

1.4.5. 4.6 пунктчасында «69,285» санын «68,35» санына алмаштырырга;

1.5. 5 «Территорияне төзекләндерү һәм яшелләндерү характеристикасы» пунктында:

1.5.1. өченче абзацта «1,92» санын «1,86» санына алмаштырырга;

1.5.2. алтынчы абзацта «3,84» санын «3,78» санына алмаштырырга;

1.5.3. сигезенче абзацта «7,68» санын «7,62» санына алмаштырырга.

2. Кызыл линияләр, социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге объектларны, капиталь төзелеш объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләре күрсәтелгән планлаштыру проекты сызымын әлеге үзгәрешләргә кушымта нигезендә бирергә.

3. VI «Территорияне план буенча үстерү чираты турында нигезләмә», бүлегендә «III этап» бүлекчәсендә, «Капиталь төзелеш объектлары исеме/фатирның торак мәйданы (кв.м)» баганасында 5 юлда «2500 урын» сүзләрен «2119 урын (1501 урынлык 1 корпус, 618 урынлык 2 корпус)» сүзләренә алмаштырырга.

---

Казан шәһәре Башкарма комитетының
2016 елның 18 гыйнварындагы 33 номерлы карары белән
расланган «Юбилей станциясе» территориясен планлаштыру һәм
ызанлау проектына кертелә торган үзгәрешләргә кушымта

